СОВЕТ БАЛТАСИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛТАЧ ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **КАРАР**

«24»декабрь 2020ел № 51

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында**

Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге Уставы нигезендә, Балтач шәһәр җирлеге Советы карар бирде:

1. Түбәндәге кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Балтач шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль җир контроле турында Нигезләмәне;

муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеген;

муниципаль җир контроленең төп күрсәткечләрен һәм аның максатчан күрсәткечләрен, муниципаль җир контроле өчен индикатив күрсәткечләрне.

2. 2009 елның 22 апрелендәге 32 номерлы карар (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру турында нигезләмә үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач шәһәр җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Балтач шәһәр җирлеге башлыгы Р.Р.Нотфуллин